КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 21 март г.Казань № 171

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 31 май, 397 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 3 июль, 534 нче; 2021 ел, 20 август, 750 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 951 нче; 2021 ел, 17 декабрь, 1245 нче; 2022 ел, 15 март, 239 нчы; 2022 ел, 13 июль, 673 нче; 2022 ел, 27 сентябрь, 1038 нче; 2023 ел, 11 февраль, 133 нче; 2023 ел, 22 июнь, 734 нче; 2023 ел, 8 сентябрь, 1114 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта:

«а» пунктчасында:

икенче абзацта «, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «, рапс» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «а» пунктчасы» сүзләрен «а» һәм «в» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 – 2030 елларга авыл хуҗалыгын үстерү буенча федераль фәнни-техник программаны раслау турында» 2017 елның 25 августындагы 996 номерлы карары белән расланган 2017 – 2030 елларга авыл хуҗалыгын үстерү буенча федераль фәнни-техник программа (алга таба – ФФТ программа) кысаларында җитештерелгән агымдагы финанс елы уңышына оригиналь орлыкларны чәчү өчен хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында сатып алуга.»;

7 пунктта:

икенче абзацта «а» пунктчасы» сүзләрен «а» һәм «в» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган, файдалануга рөхсәт ителгән Селекция казанышларының дәүләт реестрына кертелгән, сатып алынган бөртекле, азык культураларының (кукуруздан башка), кузаклы, ярма, техник культураларның (шикәр чөгендере, көнбагыштан башка) оригиналь орлыклары, бәрәңгенең оригиналь һәм элиталы орлыклары буенча, шулай ук Министрлык боерыгы белән расланган исемлек нигезендә сортлары сынала торган авыл хуҗалыгы культуралары сортлары яисә Селекция казанышларының дәүләт реестрына кертелмәгән перспективлы сортлар орлыклары буенча кайтарту (сатып алу-сату) шартнамәләре, товар накладнойлары (ТОРГ-12 нче унификацияләнгән форма), товар-транспорт накладнойлары (универсаль тапшыру документлары), түләү йөкнамәләре һәм (яисә) керем касса ордерлары, яраклылык сертификатлары һәм (яки) сынау беркетмәләре һәм (яки) чәчү сыйфатлары инспекциясе беркетмәләре, карантин сертификататлары һәм аккредитацияләнгән лабораториядән карантиядәге продукциянең (объектның) карантин-фитосанитар торышы турында бәяләмә актлары (Татарстан Республикасыннан читтәге карантинда булган зоналардан орлыклар алып кергәндә), аккредитацияләнгән лабораториядән карантиядәге продукциянең (объектның) карантин-фитосанитар торышы турында бәяләмә актлары (Татарстан Республикасыннан читтәге карантинда булмаган зоналардан орлыклар алып кергәндә);»;

бишенче абзацта «, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «, рапс» сүзен төшереп калдырырга, «рапс һәм күпьеллык үләннәр,» сүзләрен төшереп

калдырырга;

алтынчы абзацта «, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «, рапс» сүзен төшереп калдырырга, «рапс һәм күпьеллык үләннәр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14 пунктның икенче абзацында «, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «, рапс» сүзен төшереп калдырырга, «рапс һәм күпьеллык үләннәр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

«$16^1$. Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә бирелә торган субсидиянең исәпләнә торган күләме ($W_c$) (сумда) сайлап алуда катнашучы тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_c = Z_c \times 70\%,$$

$Z_c$ – ФФТ программа кысаларында башкарылган, оригиналь орлыклар сатып алуга бәйле булган өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып, агымдагы һәм (яки) хисап финанс елында факттагы сарыф ителгән чыгымнар суммасы, сум.

Шул ук вакытта субсидия күләме хисап һәм агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елының уңышы өчен югарыда күрсәтелгән чараларны үткәрүгә бәйле рәвештә фактта тотылган чыгымнар күләменнән артып китә алмый.»;

17 пунктта:

икенче абзацта «, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «, рапс» сүзен төшереп калдырырга, «, рапс, күпьеллык үләннәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә – заявка бирү датасына карата ФФТ программа кысаларында башкарылган, сатып алынган оригиналь орлыклар күләме, тонна.»;

әлеге карар белән расланган Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

6 пунктта:

бишенче абзацта «августыннан» сүзен «июненнән» сүзенә алмаштырырга, татар текстында «актив матдәгә» сүзләренә кадәр «, үсемлекләрнең туклану элементларын – азот, фосфор, калий һәм күкертне исәпкә алып,» сүзләрен өстәргә, «актив матдәгә» сүзләреннән соң «(алга таба – актив матдә)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«I яки II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучылар өчен – хисап финанс елының 1 гектар орлык чәчүлекләре өчен кимендә өч центнер орлык сату.»;

8 пунктта:

алтынчы абзацта «августыннан» сүзен «июненнән» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «агымдагы финанс елының авыл хуҗалыгы культуралары

уңышы өчен» сүзләрен «хисап финанс елының авыл хуҗалыгы культураларының орлык чәчүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «иминият шартнамәләренең күчермәләре» сүзләрен «югалткан (һәлак булган) очракка авыл хуҗалыгын иминләштерү шартнамәләре нигезендә төзелгән, иминләштерелгән чәчү мәйданнары күләме турында ирекле формада язылган мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга, «агымдагы» сүзеннән соң «финанс» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы культуралары уңышын югалткан (һәлак булган) очракка авыл хуҗалыгын иминләштерү шартнамәсе нигезендә иминият премиясен түләү өчен түләү йөкнамәсе (булганда);»;

уналтынчы һәм унҗиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү елына кадәрге авыл хуҗалыгы культуралары уңышы өчен Россия Федерациясе территориясендә кулланырга рөхсәт ителгән (Россия Федерациясе территориясендә кулланырга рөхсәт ителгән пестицидларның һәм агрохимикатларның дәүләт каталогына кертелгән) биологик пестицидлар сатуны һәм (яки) җитештерүне гамәлгә ашыручы юридик затлардан сайлап алуда катнашучыларның биологик пестицидлар сатып алуын раслый торган документлар (кайтарту шартнамәләре, кайтартулар шартнамәләре нигезендә түләү йөкнамәләре, товар накладнойлары яки универсаль тапшыру документлары) күчермәләре;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан расланган һәм «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы белән килештерелгән авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләрен биологик пестицидлар белән эшкәртү мәйданнары турында ирекле формада язылган мәгълүмат, гектарда (булганда);»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«I яки II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучылар өчен – «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы белән килештерелгән хисап финанс елының 1 гектар орлык чәчүлекләре өчен кимендә өч центнерга орлыклар сатуны раслый торган ирекле формада язылган белешмә кәгазе.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират белән теркәүгә алына.»;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = П \times S + П_{агро} \times S + П_{күпьел.үс.} \times S \times 1{,}5 + П_{күч.ф.} \times S \times 0{,}3 + П \times S \times 0{,}05 +$$
$$+ П_{им.} \times S \times 0{,}6 + П_{био.} \times S \times 0{,}3 + W_{орл.\ I\ кат.} + W_{орл.\ II\ кат.} + W_{фотосеп},$$

монда:

П – агымдагы финанс елы уңышы өчен авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре мәйданы, гектар;

S – агымдагы финанс елы уңышы өчен авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренең 1 гектар мәйданына 450,0 сумга тигез субсидия ставкасы;

$П_{агро}$ – агымдагы финанс елы уңышы өчен авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренең «Игенчелекнең туфракны саклый торган агроландшафт системасы» проектында күрсәтелгән мәйданы, гектар;

$П_{күпьел.үс.}$ – хисап елында капламлы һәм (яки) капламсыз чәчелгән күпьеллык үсемлекләрнең чәчүлекләр мәйданы, гектар;

$П_{күч.ф.}$ – агымдагы финанс елы уңышына күчә торган орлыклар фонды белән уҗым бодай культураларының чәчүлекләр мәйданы, гектар;

0,05 – субсидия алучының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында агымдагы финанс елы уңышына авыл хуҗалыгы культураларының барлык чәчүлек мәйданнарының цифрлы профиле һәм һәм тасвирнамәләре булганда кулланыла торган коэффициент;

$П_{им.}$ – агымдагы финанс елы уңышына авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренең уңышны иминләштерү шартнамәсендә күрсәтелгән мәйданнары, гектар;

$П_{био.}$ – хисап финанс елы уңышына авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренең биологик пестицидлар кулланылган мәйданы, гектар.

I категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучыларга субсидия күләме ($W_{орл.\ I\ кат.}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{орл.\ I\ кат.} = П_{орл.\ I\ кат.} \times 300{,}0,$$

монда:

$П_{орл.\ I\ кат.}$ – I категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучыда яки аның бүлегендә (бүлекчәсендә, филиалында) хисап финанс елындагы авыл хуҗалыгы культураларының орлык чәчүлекләре мәйданы, гектар;

300,0 – I категория орлыкчылык хуҗалыклары өчен хисап финанс елындагы авыл хуҗалыгы культураларының 1 гектар орлык чәчүлекләре мәйланы өчен субсидия ставкасы, сум.

II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучыларга субсидия күләме ($W_{орл.\ II\ кат.}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{орл.\ II\ кат.} = П_{орл.\ II\ кат.} \times 200{,}0,$$

монда:

$П_{орл.\ II\ кат.}$ – II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусына ия субсидия алучыда яки аның бүлегендә (бүлекчәсендә, филиалында) хисап финанс елындагы авыл хуҗалыгы культураларының орлык чәчүлекләре мәйданы, гектар;

200,0 – II категория орлыкчылык хуҗалыклары өчен хисап финанс елындагы

авыл хуҗалыгы культураларының 1 гектар орлык чәчүлекләре мәйланы өчен субсидия ставкасы, сум.

I яки II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусы Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларына Министрлыкның «Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусын бирү турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 417/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы оешмаларына I яки II категория орлыкчылык хуҗалыгы статусын бирү турындагы нигезләмә буенча бирелә.

Статус өч елга бер тапкыр раслана һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

Ашлык бөртеген чистарту һәм сортларга аеру өчен субсидия алучы фотосепаратор сатып алганда субсидия алучыларга субсидия күләме (ашлык бөртеген чистарту һәм сортларга аеру өчен фотосепаратор берәмлеген сатып алырга бер тапкыр исәпләнә һәм 3,0 млн.сумнан арта алмый) ($W_{фотосеп}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{фотосеп} = П_{орл.} \times S \times 4{,}0,$$

монда:

$П_{орл.}$ – субсидия алучының агымдагы финанс елы уңышына авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре мәйданы, гектар;

4,0 – ашлык бөртеген чистарту һәм сортларга аеру өчен субсидия алучы фотосепаратор сатып алганда кулланыла торган коэффициент.»;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта:

«г» пунктчасында «бәрәңге» сүзеннән соң «һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) сүс җитене һәм (яки) техник киндер җитештерүне стимуллау.»;

җиденче абзацта «Урта Идел төбәгендә файдаланырга рөхсәт ителгән» сүзләрен төшереп калдырырга, «33996-2016 нчы ГОСТ», «(алга таба – районлаштырылган орлыклар)» сүзләрен «33996-2016 нчы ГОСТтагы бәрәңге өчен, 32592-2013 нче ГОСТтагы, 30106-94 нче ГОСТтагы, 32917-2014 нче ГОСТтагы ачык грунт яшелчә культуралары өчен» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

дүртенче абзацта «, бәрәңге» сүзен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә субсидия алу өчен – җитен саламын һәм (яки) киндер саламын Россия Федерациясе территориясендә урнашкан эшкәртүче оешмаларга сатуны һәм (яки) үз эшкәртүгә төяп җибәрүне гамәлгә ашыру.»;

7 пунктта:

унберенче абзацка «, җирләрне химик мелиорацияләү өлкәсендә чаралар

үткәрелгән җир кишәрлекләренә милек (файдалану, арендага алу) хокукын раслый торган документ күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацка «бәрәңгенең» сүзеннән соң «һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының» сүзләрен өстәргә, «шул исәптән бәрәңгенең районлаштырылган орлыкларының» сүзләрен төшереп калдырырга;

унбишенче абзацта «орлык бәрәңгесе,» сүзләреннән соң «ачык грунт яшелчә культуралары орлыклары,» сүзләрен өстәргә;

унтугызынчы һәм егерменче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә субсидия алу өчен сайлап алуда катнашучы агымдагы финанс елында сүс җитенен һәм (яки) техник киндерне чәчү мәйданы һәм (яки) чәчергә планлаштырыла торган мәйдан турында ирекле формада язылган өстәмә мәгълүмат бирә.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират белән теркәүгә алына.»;

13 пунктта:

бишенче абзацка «һәм (яки) ачык грунт яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә – минераль ашламалар, орлыклар, үсемлекләрне саклау чаралары, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алуга, амортизациягә, хезмәт өчен түләүгә, чит оешмаларның хезмәт күрсәтүләренә, сүс җитене һәм (яки) техник киндер җитештерүгә бәйле агротехнологик эшләр башкаруга фактик чыгымнар.»;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{к.ов.}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{бәр.яшел.} = P_{агым.ел} \times 25\,000 + W_{бәр.яшел.арт},$$

монда:

$P_{агым.ел}$ – агымдагы финанс елында бәрәңге һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының чәчү мәйданы, гектар;

25 000 – агымдагы финанс елында бәрәңгенең һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының чәчү мәйданына субсидия ставкасы, сум;

$W_{бәр.яшел.арт}$ – хисап финанс елына карата агымдагы финанс елында бәрәңгенең һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының чәчү мәйданнарын арттырганда субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (сумда) түбәндәге формула буенча

билгеләнә:

$$W_{бәр.яшел.арт} = (P_{агым.ел} - P_{хис.ел}) \times 15\ 000,$$

монда:

$P_{хис.ел}$ – хисап финанс елында бәрәңгенең һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының чәчү мәйданы, гектар;

15 000 – хисап финанс елына карата агымдагы финанс елында бәрәңгенең һәм (яки) ачык грунт яшелчә культураларының арттырылган чәчү мәйданнары өлешенә субсидия ставкасы, сум.

Шул ук вакытта субсидия күләме хисап финанс елының 1 августыннан алып һәм агымдагы финанс елында үткәрелгән сайлап алуда катнашу өчен гариза бирелгән датага кадәр бәрәңге җитештерүгә бәйле факттагы чыгымнар күләменнән арта алмый.»;

түбәндәге эчтәлекле $17^2$ пункт өстәргә:

«$17^2$. Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{җитен}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{җитен} = P_{җитен} \times 35\ 000,$$

монда:

$P_{җитен}$ – агымдагы финанс елында сүс җитененең һәм (яки) техник киндернең чәчү мәйданы, гектар;

35 000 – агымдагы финанс елында сүс җитененең һәм (яки) техник киндернең чәчү мәйданына субсидия ставкасы, сум.

Шул ук вакытта субсидия күләме агымдагы финанс елында сүс җитене һәм (яки) техник киндер җитештерүгә бәйле тотылган факттагы чыгымнар күләменнән арта алмый.»;

18 пунктта:

бишенче абзацта «бәрәңге» сүзеннән соң «һәм (яисә) ачык грунт яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 1 июленә карата агымдагы финанс елы уңышы өчен сүс җитененең һәм (яки) техник киндернең чәчү мәйданы, гектар.»;

әлеге карар белән расланган Органик продукция җитештерүне үстерү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктның дүртенче абзацына татар текстында «сайлап алуда катнашучының милкендә (файдалануында, арендасында)» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «транспорт чараларын ремонтлау,» сүзләреннән соң «газ куллану челтәре объектларын эксплуатацияләү һәм аларга техник хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен түләү,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының торак пунктларына барып сатуны һәм көндәлек товарларны алып баруны гамәлгә ашыруга махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итү өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 7 пунктындагы дүртенче абзацына «кредит оешмасының вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер белән расланган» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Җитештерү егәрлекләрен модернизацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен икмәк пешерү предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта:

«б» пунктчасында «2018» саннарын «2019» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасын өстәргә:

«г) җиһаз һәм автотранспорт кайтарту (сатып алу-сату), финанс арендасы (лизинг, сублизинг) шартнамәсе төзелү елына кадәрге ике елдан да иртәрәк булмаган вакытта җитештерелгән.»;

7 пунктта:

тугызынчы абзацта «йөкнамәләре,» сүзе алдына «кредит оешмасының вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер белән расланган,» сүзләрен өстәргә;

унсигезенче абзацта «2018» саннарын «2019» саннарына алмаштырырга, «, технологик җиһазны субсидияләгәндә файдалануга тапшыру акты» сүзләрен өстәргә;

унтугызынчы абзацта «түләү» сүзе алдына «, кредит оешмасының вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер белән таныкланган» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта:

беренче абзацка «(алга таба – техника)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «, шул исәптән үзйөрешле сиптергечләр» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юл, коммуналь, төзелеш, хәрби, янгын сүндерү, медицина, урман әзерләү техникасыннан тыш, вагон-цистерналар, махсус, махсуслаштырылган һәм йөк транспорты;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытка сатып алынган сыек ашламалар әзерләү җайланмалары, туфрак инъекторлары (сыек ашламалар кертү агрегатлары), үз илебездә җитештерелгән сыек комплекслы ашламалар саклау резервуарлары.»;

«а» пунктчасына «әлеге пунктның тугызынчы абзацында күрсәтелгән техникадан тыш» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта:

сигезенче абзацта «йөкнамәләре» сүзен «банк документлары һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документлар» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «югарыда күрсәтелгән орган тарафыннан таныкланган амортизация срогына хокук кучүне чикләү турында белешмә» сүзләрен төшереп калдырырга;

унҗиденче абзацта «йөкнамәләре» сүзен «банк документлары» сүзләренә

алмаштырырга;

12 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сатып алынган сыек ашламалар әзерләү җайланмалары, туфрак инъекторлары (сыек ашламалар кертү агрегатлары), үз илебездә җитештерелгән сыек комплекслы ашламалар саклау резервуарлары, үзйөрешле сиптерүчеләр өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_2$) (сумда)түбәндәге формула буенча билгеләнә:»;

ундүртенче абзацта «елларында» сүзләре алдына «, 2024 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытта сатып алынган сыек ашламалар әзерләү җайланмалары, туфрак инъекторлары (сыек ашламалар кертү агрегатлары), үз илебездә җитештерелгән сыек комплекслы ашламалар саклау резервуарлары» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Эрозиягә каршы һәм кырларны саклау өчен урман утыртмаларын утыртуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

8 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эрозиягә каршы һәм кырларны саклау өчен урман утыртмаларын утырту планлаштырылган җир кишәрлекләренә милек (файдалану, арендалау) хокукын раслый торган документлар (хокукны теркәү турында таныклык, җир кишәрлеген арендалау яки файдалану турында шартнамә (килешү)) күчермәләре;»;

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Мелиорация системаларын, аерым урнашкан гидротехник корылмаларны һәм саклый торган урман утыртмаларын файдалануга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 апрелендәге 175 номерлы боерыгы белән расланган Мелиорация системаларын, аерым урнашкан гидротехник корылмаларны һәм саклый торган урман утыртмаларын файдалануга кабул итү тәртибенә теркәлгән кушымта нигезендә, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы җирләрне мелиорацияләү һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү буенча федераль дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, саклый торган урман утыртмаларын файдалануга кабул итү акты күчермәсен.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин